РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА
Татарско-Шуганского сельского
поселения Азнакаевского
муниципального района

ул. Советская, д. 41в , село Татарский
Шуган, Азнакаевского
муниципального района, 423327
Тел. (факс) (85592) 36-1-41
Tshug .Azn @tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай
муниципаль районы Татар Шуган
авыл җирлеге Советы
БАШЛЫГЫ

Совет урамы, 41в, Татар Шуган
авылы Азнакай муниципаль районы,
423327
Тел. (факс) (85592) 36-1-41
Tshug .Azn @tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» октябрь 2025 ел №2

2026 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Татар Шуганы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Татар Шуганы авыл җирлеге Уставы нигезендә , карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Татар Шуганы авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2025 елның 30 октябрендә 10 сәгать 00 минутка үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Билгеләргә:
   - Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Татар Шуганы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Башкарма комитеты;
   - гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 30 октябрь 2025 ел 10.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр;
   - үткәрү урыны – Татар Шуганы авылы, Совет ур., 41б йорт;
3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2025 елның 21 октябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Татар Шуганы авылы, Совет урамы, 41в йорт;
- сайлау хокукына ия булган Татар Шуганы торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Татар Шуганы торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

4. «Сез, 2026 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, махсус хәрби операцияләрдә катнашучылардан һәм аларның гаиләләре әгъзаларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 200 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Татар Шуганы авылында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

1) торак пункт чикләрендә җирле мәгънәдә гомуми файдаланучы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Яшьләр урамында юлларга вак таш җәю , сатып алу, ташу, вак таш салу).

« РИЗА» «КАРШЫ».

5. Әлеге карарны, Татар Шуганы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык М.Ш.Хәертдинов